**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

«26» октябрь 2022 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 26 октябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылында яшәүче, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Иске Татар Әмзәсе авылындагы зират территориясен төзекләндерү;

- Иске Татар Әмзәсе авылында зиратның хуҗалык инвентарен саклау өчен павильон сатып алу һәм урнаштыру мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 125 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 74 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 74 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылында яшәүче, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Иске Татар Әмзәсе авылындагы зират территориясен төзекләндерү;

- Иске Татар Әмзәсе авылында зиратның хуҗалык инвентарен саклау өчен павильон сатып алу һәм мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының

Әмзә авыл җирлеге Иске Татар Әмзәсе авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Ә.Ф.Сафиуллина

Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина